| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 Баулы шәһәре № 39

2021 елга Баулы муниципаль районы
муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның
фараз планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы федераль Законнар нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 1нче кушымта нигезендә, 2021 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына 2021 елга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы муниципаль районы Советының
2021 елның
18.02.
39нчы номерлы карарына
1нче кушымта

2021 елга Баулы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2021 елга Баулы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнгән.

1.2. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Баулы муниципаль районы муниципаль милек структурасын оптимальләштерүгә, хосусыйлаштыру объектларына инвестицияләр җәлеп итүгә, район бюджеты керемнәрен арттыруга, муниципаль милек объектларын тотуга җирле бюджет чыгымнарын киметүгә, муниципаль милекне хосусыйлаштырудан кергән акчалар исәбеннән җирле бюджетны тулыландыруга, эшкуарлык эшчәнлеген үстерүгә булышлык итүгә юнәлдерелгән.

1.3. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында»гы 2016 елның 13 июлендәге 66 номерлы карары нигезендә тормышка ашырыла, хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясенә таянып билгеләнә.

2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

2.1. Баулы муниципаль районының муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәт хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. 2020 елга Баулы муниципаль районын хосусыйлаштыруның фараз планына (программасына) кертелгән һәм хосусыйлаштыру узмаган объектлар хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.3. Муниципаль милектәге муниципаль казна предприятиеләрен һәм акцияләрен 2021 елда хосусыйлаштыру планлаштырылмый.

2.4. 2021 елда хосусыйлаштыруга планлаштырылган муниципаль мөлкәт исемлеге хосусыйлаштыруның фараз планы гамәлдә булган чорда яңа күчемсез милек объектлары белән тулыландырырга мөмкин.

2.5. 2021 елда хосусыйлаштырылырга тиеш муниципаль мөлкәт (1нче таблица).

1нче таблица

| № п/п | Объект атамасы | Урнашу урыны |
|---|---|---|
| 1. | Торак булмаган бина, S- 144,6 кв.м. 16:55:010105:6603 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы ш., Пионер ур., 9А й. |
| 2. | Җир участогы, S – 567 кв.м., 16:55:010105:6481 | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы ш., Пионер ур., 9А й. |
| 3. | Гараж бинасы, 16:55:010104:1322:0123, S- 340,9 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы ш., ОРС гаражы |
| 4. | Җир участогы, 16:55:010104:1322, S- 2766,0 кв.м. | Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Баулы ш., ОРС гаражы |